**ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**«03» сентябрь, 2021 ел** **№ 79**

**Биектау муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 11 февралендәге 26 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Биектау муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 11 февралендәге 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы Вазыйфасы инструкциясенә (Башлыкның 10.02.2020 № 9 карары редакциясендә), 3.3 пунктның 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«7) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;».

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Р.Г.Кәлимуллин